ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО АРХИВНОМУ ДЕЛУ
Ново-Песочная ул., д. 44, г. Казань, 420107

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ АРХИВ ЭШЕ БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ
Ново-Песочная ур. 44 нчы йорт, Казан шәһәре 420107

# БОЕРЫК

27.01.2020 Казан шәһәре № 16-од

Татарстан Республикасында һәр елны «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә бәйрәме уздыру турындагы 21.10.2019 датасы һәм 190 нчы номер белән Татарстан Республикасы Дәүләт архивы тарафыннан расланган «О празднике родословной «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында

Буыннар арасындагы бәйләнешләрне саклау һәм үстерү, гаиләдәге мөнәсәбәтләрне ныгыту, киң җәмәгатьчелекнең Татарстан Республикасы һәм үз нәсел шәҗәрәсе тарихына кызыксынуы артсын өчен, б о е р а м:

Татарстан Республикасында һәр елны «Эхо веков в истории семьи – Тарихта без эзлебез» шәҗәрә бәйрәме уздыру турындагы 21.10.2019 датасы һәм 190 нчы номер белән Татарстан Республикасы Дәүләт архивы тарафыннан расланган «О празднике родословной «Эхо веков в истори семьи – Тарихта без эзлебез» Нигезләмәсенә үзгәрешләр кертү турында:

3 нче бүлекнең 3.3. нче пункты. Нигезләмәдәге «Бәйрәмне оештыру» өлешен түбәндәге редакциядә тәкъдим итәргә:

«3.3. Бәйрәм 3 этаптан гыйбарәт: муниципаль, зона һәм республика этаплары»;

Нигезләмәнең 4 нче бүлеген түбәндәге редакциядә тәкъдим итәргә:

«4. Бәйрәмне уздыруның гомуми шартлары.

Бәйрәмнең зона этабын уздыруның
төп шартлары һәм кагыйдәләре».

4.1. Бәйрәм 3 этаптан гыйбарәт: муниципаль, зона һәм республика этаплары.

4.2. 1 нче этап – муниципаль этап – ул Татарстан Республикасының муниципаль берләшмәләрендә уздырыла. Уздыру сроклары – 19 февральдән алып 30 мартка кадәр тәкъдим ителә, әлеге сроклар һәм кагыйдәләр муниципаль хокукый актлар белән билгеләнгән (алга таба – муниципаль этап).

Бәйрәмнең муниципаль этабындагы конкурсларда катнашучылар, беренче урынны яулаган хәлдә, Бәйрәмнең зона этабына җибәрелә.

4.3. 2 нче этап – зона этабы – ул Татарстан Республикасы муниципаль берләшмәләрендә 6 апрельдән алып 13 апрельгә кадәр зона этабы узачагы турында муниципаль берләшмә җитәкчеләре белән алдан килешенгән график буена уздырыла.

Бәйрәмнең зона этабы Татарстан Республикасының архив эше буенча Дәүләт комитеты һәм Татарстан Республикасы муниципаль берләшмәләренең җирле үзидарәсе органнары белән берлектә 6 зонага (алга таба – зона этабы) бүлеп уздырыла:

1 нче зона. Әлмәт шәһәре (Лениногорск, Әлмәт, Азнакай, Баулы, Бөгелмә, Мөслим, Сарман, Чирмешән, Ютазы районнары);

2 нче зона. Актаныш (Актаныш, Әгерҗе, Зәй, Алабуга, Минзәлә, Менделеевск, Тукай муниципаль районнары һәм Яр Чаллы шәһәре);

3 нче зона. Балык Бистәсе (Алексеевск, Чистай, Әлки, Лаеш, Нурлат, Яңа Чишмә, Балык Бистәсе, Спас, Чистай муниципаль районнары);

4 нче зона. Биектау (Арча, Әтнә, Балтач, Биектау, Кукмара, Мамадыш, Питрәч, Саба, Теләче муниципаль районнары);

5 нче зона. Апас (Тәтеш, Апас, Югары Ослан, Яшел Үзән, Кайбыч, Кама Тамагы, Чүпрәле муниципаль районнары);

6 нчы зона. Казан шәһәре (Авиатөзелеш, Вахитов, Киров, Мәскәү, Яңа Савин, Идел буе, Совет районнары).

Зоналар (муниципаль берләшмәләр) Бәйрәм уздыру барышында ел саен махсус график буенча үзгәрәчәк.

4.4. 3 нче этап – республика этабы. Ул Татарстан Республикасы Архив эше буенча Дәүләт комитеты тарафыннан 15 апрельдән алып 15 майга кадәр уздырылачак (алга таба – республика этабы).

Республика этабына йомгаклар 15 майда ясала.

4.5. Бәйрәмне зона этабында уздыруның тәртибе.

4.5.1. Бәйрәмнең зона этабында муниципаль этаптан узган бер гаилә коллективы (гаилә, туганлык җепләре бәйләгән коллектив) (3 кешедән дә кимрәк булмаска тиеш, катнашучыларның максималь саны чикләнмәгән) катнаша ала.

Әлеге Нигезләмәнең 4.3. нче пунктында күрсәтелгән буенча, яшь буенча чикләр ассызыкланмаган, бу коллективта берничә буын вәкиле берләшкән булуы шарт, шул ук вакытта коллективның милли тәгаенлеге һәм нинди диндә булуы – мөһим түгел.

4.5.2. Бәйрәмнең зона этабы программасы үз эченә 2 блокны ала, болар жюри әгъзалары тарафыннан алдан билгеләнгән критерийлар буенча (әлеге Нигезләмәгә 1нче кушымтада күрсәтелгән) бәяләнә:

1) Милли һәм гаилә ризыклары күргәзмәсе (пешкән ризыклар һәм үзенчәлекле ашлар);

2) «Таныш булыгыз, минем гаиләм, минем нәселем!» - гаилә командалары бәйгесе – биредә команда үзенең визит карточкасын тәкъдим итә, ул нәсел шәҗәрәсен күрсәтүне максат итеп куйган үзенчәлекле концерт номерын үз эченә алырга тиеш. Номер ирекле формада оештырыла: бию, җыр, театральләштерелгән тамаша һ.б. Шулай ук ул гаилә милли костюмын тәкъдир итү рәвешендә дә булырга мөмкин.

Гаилә шәҗәрә агачы династияләрне, гаилә архивында сакланган материалларны, ядкарьләрне, коллекцияләрне тәкъдир итү рәвешендә булырга тиеш, шулай ук ул үз эченә кызыклы фактларны, гаилә риваятьләрен дә алса – бик яхшы. Бизәлеше альбом, стенд, панно, баннер-коллаж кыяфәтен алырга мөмкин, анда шәҗәрәне раслаучы текст рәвешендәге нигезләмәнең барлыгы шарт;

Һәр команда өчен куелган регламент: 10 минут.

4.5.3. Массакүләм мәгълүмат чараларында Бәйрәмне яктырту оештырыла, район һәм шәһәр вакытлы матбугат басмаларында шәҗәрәләрнең басылып чыгуы зарур.

4.6. Бәйрәмнең зона этабы конкурсында катнашучылар, беренче урынны яулап, Бәйрәмнең республика этабына уза.

1. Әлеге Боерыкның үтәлүен контрольдә тоту хокукын үз өстемә алам.

Рәис Г.З. Габдрахманова